# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 17.11.2021

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Димитарлау авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә ТР Законының 17 ноябрендә «2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Димитарлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә риза буласызмы?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, моннан тыш, 1 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн олкэннэрдэн, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Димитарлау авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;
- Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүченең эш хакы, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Димитарлау авылынын М. Җәлил урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу);

«ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 84 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 47 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 47 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегендә узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский завод авыл җирлеге Димитарлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән вакытлы хәрби хезмәт узучы, 1

төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн олкэннэрдэн, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2022 елда үзара салым кертергә риза:

-- Димитарлау авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;

- Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүченең эш хакы, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Димитарлау авылынын М. Җәлил урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу);

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Петровский Завод авыл җир-леге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы __________ А.Б. Хөснетдинов